БУРАН

Тик кенә торганда капланды томанга бар һава;
Кар оча, кар себреләә, кар котрына һәм кар ява.

Кар бәрә йөзгә рәхимсез, күз ачып булмый карап;
Һәр кара нәрсә бүре һәм һәр маяк булды карак.

Карны җиңгән күк, төшә җиргә тонык ай яктысы;
Ай да куркынган шикелле: бер сары, бер ак төсе.

Сукранам мин, кар арасыннан карый да ай көлә.
Мин фәкыйрь михнәттә — гүя чарлагыннан бай көлә!



Бөтендөнья балалары, дуслашыгыз!

Сабантуй

28 февраль, 1996 ел
№ 17
(4733)

Балалар һәм яшүсмерләр газетасы



2-3 битләр, әдәбият сөючеләр, сезнең өчен.

"Трамвай кая бара?"— ди "Шаянтуй" сәхифәсе.

4 бит

Илдә нилэр бар икән?

Мәскәүдә язучылар оешмаларының халыкара союзында Муса Җәлилнең юбилеена багышланган очрашу үткәрелде. Безнең бөек шагыйребезне башкалада шулай искә алу бик күңелле күренеш, әлбәттә. Әле алай гына түгел — 25 февральгә кадәр Мәскәүдә "Җәлил көннәре" барды.

•••

Дәһшәтле сугыш гарасатларыннан исән калган Первомайское авылында (Дагыстан) һәркемгә берәр миллион пособие бирелгән.

•••

Бер үк көнне ике космодром сугышчан хәрәкәткә килеп, Байконурда элемтә ракетасы, ә Плисецкида алты спутник галәмгә очырылган.

Шундый чиста күк йөзе,
Бетерсәң лә кар үзе.
Үзе матур, үзе ак,
Үзе чиста, үзе пакъ.

Рамиз Рафиков
Сарман, Җәлил

КАР БӨРТЕГЕ

Кар бөртеге кулга куна,
Челт-челт итеп күзен йома.
"Бәхет телим сезгә",— ди ул
Һәм шунда ук юкка чыга.

"Яше" калды кулларымда,
"Сүзе" калды колагымда.
Кар кызының бу теләге
Бүләк булды Яңа елга.

Гөлнара ХӘБИБУЛЛИНА.
6 нчы класс.
Арча, Түбән Аты.

ӨЙРӘТТЕҢ СИН...

Өйрәттең син мине яратырга
Туган җиремне һәм илемне.
Искә төшердең син, укытучым,
Онытыла язган телемне.

Зөлфия ГАЛИМҖАНОВА.
Казан, 23 нче мәктәп-гимназия.



ТӨШ

Төшемдә мин очам аккош булып,
Иңләп-буйлап очам һавада.
Аккош булып очкан вакытларым
Күз алдымда минем һаман да.

Аккош булып очып китәм дә мин,
Татлы төшем шунда өзелә.
Аккош булып күтәрелгәч кенә,
Җирем тартып ала үзенә.

Гөлгенә ӘҺЛИУЛЛИНА.
Саба, Яңа Мичән.

ЯРАН ГӨЛ ЧӘЧӘКЛӘРЕ

Су сибәм мин гөлләремә,
Иркәләп һәм яратып.
Иркәләгәнне сизәләр,
Хуш исле чәчәк атып.

Яран гөлнең чәчәкләре
Ал, кызыл һәм ак була.
Гөлләр белән серләшкәндә
Күңелгә шатлык тула.

Рәмзия ХӘЙРЕТДИНОВА.
5 нче класс.
Әлмәт, Бишмунча.

ЧИШМӘ

Әбиемнәр авылында
Бар саф сулы бер чишмә.
Әбекәйләр, бабакайлар
Шул чишмәдән су эчә.

Торба аша килеп җитә
Авылга үк чиста су.
Бер чишмәдән эчкәнгәме —
Халык монда бик тату.

Мактанырга исәбем юк,
"Арттыра бу",— димәгез.
Яман уйларыгыз белән
Сез чишмәгә килмәгез!

Рамилә ХӘБИРОВА.
8 класс.
Актаныш, Чалманарат.

КИТАП

Илдар укый китапны,
Нигә укый шулчаклы?
Укый ул түмән белеп,
Укый ул ямен белеп.

Китап укыган кеше
Тормышны аңлый белә.
Күп белә шул, күп белә,
Күп укый шуңа күрә.

Рамил ХӘБИРОВ.
3 класс.
Актаныш, Чалманарат.

ӘБИЕМ

Бар минем бер әбием,
Исемнәре Гөлсинә,
Иртүк торып,
чәйләр эчеп,
Китеп бара эшенә.

Әбиемне бик яратам,
Син безгә бик кирәк, дим,
Авырмыйча, озак яшә,
Миннән сиңа теләк, дим.

Әлфинә ГАЗАКАЕВА,
6 нчы класс.
Әгерже, Сарсак-Омга агролицее.

Шигырь язган идем. Үземә бик ошады. Уйладым да, "Сабантуй" дустым, сиңа җибәрергә булдым. Әгәр синең битләреңдә басылса, мин һәрвакыт синең белән дус булырмын, яме?

ЯҢА ЧАҢГЫ

Әти миңа Казаннан
Чаңгылар алып кайтты.
Шундый матур чаңгылар —
Әнием дә яратты.

Яңа чаңгы яңа шул,
Таудан оста шуа ул.
Егылганым юк әле —
Сөенечем зур әле!

Алия МӨБАРӘКШИНА.
2 класс.
Әлмәт, Бишмунча.

КОМПЬЮТЕР

Туган көнемә әнием
Сатып алды компьютер.
Рәхәтләнеп, төймәсенә
Баскалап кына утыр.

Компьютердан компьютерга
Килә хәзер күчәсем,
Кнопкага басып кына
Килә тизрәк үсәсем.

Рамил ХӘМИДУЛЛИН.
Әгерже, Иж-Бубый.

Күп нульләрдән
торган санны
Укый гына алабыз.
Зур бәяле әйберләргә
Юк бит безнең чамабыз.

Бала гына дип әйтмәгез,
Без дә өмет итәбез:
Өлкәннәрнең безгә таба
Борылуын көтәбез.

Фәнил ХӨСӘЕНОВ.
6 нчы класс.
Арча, Штерә.

КӨТӘБЕЗ...

"Һәр яхшыны — балаларга!" —
Диеп күпме әйттегез.
Кабат-кабат әйтә торгач,
Әллә сез оныттыгыз?

РОЗА

Роза чәчәге төшергән
Апамның күлмәгенә.
Сокланып карап туялмыйм
Мин аның гөлләренә.

Гөлләре дә күлмәге күк
Зур кызыл чәчәк аткан.
Рәсемгә төшереп куйдым,
Роза — минем яраткан.

Азат ӘБЕЛХАНОВ.
Буа, Ташкичү.

Безнең яраткан әдипләребез

Нурихан Фәттах



АНЫҢ ТУРЫНДА

НУРИХАН ФӘТТАХ дигәч, бүгенге укучы хәтерендә, иң башта, югары сәнгатьчә осталык белән эшләнгән тарихи романнар яңара... Нурихан Фәттах һәм бүгенге татар җәмгыятенең үзара мөнәсәбәтен аңларга тырышсаң, соңгы берничә дистә елда бу әдипнең рухи тәэсирен ачык тоясың...

Азат Әхмәдуллин,
профессор, Казан университетының татар әдәбияты кафедрасы мөдире.

НУРИХАН ФӘТТАХ әсәрә кулыма килеп кергәч, тетрәнеп тә, сокланып та бер утыруда диярлек укып чыктым... Әйе, мондый рәхимсез, туры язылган әсәрнең журналда гына түгел, гомумән, ул чор әдәбиятында булганы юк иде әле... Турыдан-туры әйтергә кирәк: Н. Фәттах, сәләтле язучы буларак, ул чорда ук әлеге кырыс хакыйкатьне тойган, аңлаган, образлы рәвештә күрсәтеп тә бирә алган. («Кырык дүртнең май аенда» исемле повесть турында сүз бара.)

Рафаэль Мостафин,
язучы, тәнкыйтьче.

«СЫЗГЫРА торган уклар» — язучының зур уңышы. Бу әсәрне мин һич шикләнмичә әдипнең ярты гасыр дәвамындагы иҗатының иң бөек ноктасы, тәп китабы дип саныйм... Н. Фәттах — тынгысыз рухлы, кабул ителгән рәсми догмалар белән килешмичә, алар белән бәхәсләшеп, көрәшеп яшәүче әдип.

Нил Юзиев,
Татарстан Фәннәр академиясенең әгъза-корреспонденты, филология фәннәре докторы.

НУРИХАН ФӘТТАХ телнең мөмкинлекләрен армый-талмый эзләүчеләрдән, телгә ифрат дәрәҗәдә сак караучылардан берсе. Тел культурасын өйрәнү мөмкинлекләрен ачу, телне үстерү — язучының үз эшенә һәм укучыларына ихтирамы дигән сүз.

Мөхәммәт Мәһдиев,
Татарстанның халык язучысы.

КҮРЕНЕКЛЕ норвег галиме Тур Хейердалның нәкъ Нурихан-Фәттах куйган максат белән, салга утырып Көньяк Америка материгыннан Полинезия атауларына, аннан соң камыштан үргән көймәдә Африкадан Америкага ясаган сәяхәтләрен хәтерли торгансыздыр? Бу ике галимнең максатлары уртак — халыкларны бер-берсеннән аеруга, бераүләрне цивилизацияле, мәдәниятле, ә икенче халыкларны артта калган һәм кыйәчсез итеп күрсәтү өчен төзелгән психологик киртәләрне җимерү теләге иде. Бу эштә мин татар галименең эшен югарырак куям, чөнки Тур Хейердалның сәяхәтләрен барлык Европа һәм Америка зыялылары күзәтеп, аңа ярдәм итәргә әзер тордылар. Нурихан исә шушы катлаулы һәм авыр эшен тулысынча ялгызлыкта, тулысынча дирлек дошманлык мохитендә башкарды.

(Фест дисбесен уку һәм, гомумән, «Шәҗәрә» китабы турында сүз бара).

Миргазиян Юныс, язучы.

ҮЗЕБЕЗГӘ КАЙТАБЫЗ

Нурихан Фәттахка

Утыртмадылар түрләргә,
Чөймәделәр күкләргә...
Аның телле-тешле сүзе
Ошамады күпләргә.

Анда әле Болгар исән,
Казан да алынмаган.

Анда әле безнең тарих
Көл белән күмелмәгән.
Анда әле минем телем

ТОРМЫШ ЮЛЫ

Нурихан Садрилмән улы ФӘТТАХ 1928 елның 25 октябрендә Башкортстанның Яңавыл районындагы Кучтавыл дигән авылда туа. 1934 елда аның әтисе үлә, шуннан соң ике ел үткәч, алар әнисенең туган авылы Янтыкка (Яңа Уртавылга) кайтып китәләр. Җиденче класска кадәр Нурихан Яңа Уртавыл мәктәбендә укый, урта мәктәпне Яңавылда тәмамлый. 1946 елда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә һәм 1951 елда аны кызыл диплом белән тәмамлый. Бер-ике ел дәвамында төрле редакцияләрдә (Татарстан китап нәшрияты, Чистай өлкә газетасы) эшләгәннән соң, 1953 елдан профессиональ язучылык эшенә күчә.

Н. Фәттах мәктәптә укыганда ук әдәбият, иҗат белән кызыксына башлый, стена газеталары, кулдан язылган журналлар чыгаруда катнаша. «Кыш» дип аталган беренче шигырен ул өченче класста укыганда яза. Район газетасында беренче шигыре 1944 елда, 1945 елда берничә шигыре Казанда «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналында дөнья күрә. 1948 елда «Безнең хикәяләр» җыентыгында беренче хикәясе басыла.

Университетта уку елларында әдәбият һәм халык иҗаты белән ныклап кызыксына башлый. 27 яшендә ул «Сезнеңчә ничек?» исемле беренче романын тәмамлый. Н. Фәттах 1948 елда Татарстанның көнчыгыш районнарында фольклор экспедициясендә, укуын тәмамлагач исә Болгар җирендә археологик казу эшләрендә катнаша. Казахстан далаларында чирәм җирләрне үзләштерү башлангач, Н. Фәттах ике ел рәттән берничә ай буе Павлодар өлкәсендә эшли, җирле халыкларның тормыш-көнкүреше белән якыннан таныша, эшчеләрнең хезмәтен өйрәнә. Нәтиҗәдә 1962 елда язучының «Бала күңеле далада» исемле яңа романы языла.

1974 елда Н. Фәттах Монголиягә иҗат командировкасына бара. Әдипнең «Бала күңеле далада», «Әтил суы ака торур», «Сызгыра торган уклар», «Кол Гали» һәм башка әсәрләре әнә шул күпьеллык эзләнүләр нәтиҗәсе булып тора.

Н. Фәттах — Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге дәүләт бүләге лауреаты.

БАСЫЛГАН КИТАПЛАРЫ

ПРОЗА ӘСӘРЛӘРЕ

«Сезнеңчә ничек?» — роман (1957)
«Берничә хикәя» — җыентык (1959)
«Бала күңеле далада» — роман (1966)
«Яшь чакларда» — хикәяләр җыентыгы (1967)
«Мөдир Сәҗидә» — повесть (1968)
«Әтил суы ака торур» — тарихи роман (1972)
«Сызгыра торган уклар» — тарихи роман, беренче китап (1984)
«Сызгыра торган уклар» — тарихи роман, икенче китап (1988)
«Шәҗәрә» — тарихи-лингвистик эзләнүләр (1990)
«Кичү» — чәчмә әсәрләр (1995)

СӘХНӘ ӘСӘРЛӘРЕ

«Энҗеле үрдәк» — Курчак театрында куелды (1973)
«Кол Гали» — Академия театрында куелды (1973)
«Сармат кызы Сәринә» — Әлмәт театрында куелды (1986)

БАЛАЛАР ӨЧЕН

«Тегермәндә». (1957).
«Өч туган». (1961).
«Ирек, Алмас һәм Җәлил». (1966).

Без табындык күкрәккә,
Ул — күктәге йолдызга.

Ул барасы юл читендә
Маяклар кабынмаган.

Кем килмәде, кем китмәде,
Кем булмады атабыз?!
Менә бүген без яңадан
Хәр мәмләкәт ханлыгында —
Нуриханга кайтабыз!

Разил ВӘЛИЕВ.



Әнисе Салиха Яңавыл мәктәбе укучылары белән. (Сулдан икенче). 1941 ел.



Нурихан (сулдан өченче) — башлангыч класс укучысы. 40 нчы еллар.



Беренче рәттә: Н. Фәттах һәм Эдуард Касыймов 1956 ел.

Кайгырма, Кол Гали, зарланма язмыштан —
Тузаннар мең төрле матдәдән яралган:

Берәүләр тусалар агачтан я таштан,
Берәүләр ялкыннан буленеп таралган.

Кайгырма, туганым, зарланма язмыштан.
Бик кыска гомерле булсаң да тумыштан.

Кызганмый үзеңне балкып ян һәм яндыр,
Гасырлар күгендә ялкынлы эз калдыр!

Буыннан- буынга нәселең таралсын,
Үтердем аны дип Газраил алдансын.

«Кол Гали» трагедиясеннән Кол Гали монологы.



Фәнни китапханәдә. 1981.



Н. Фәттах һәм аның хатыны медицина фәннәре кандидаты Руфинә ханым. 1989.



Якташлары: Нил Юзиев, Риза Ишморат һәм Нурихан Фәттах. 1993.


«Саба» 1992
«Башкорт һәм башкырт» 1992.

Н. ФӘТТАХ ӘСӘРЛӘРЕ РУСЧА ТӘРҖЕМӘДӘ

«А как по-вашему?». 1961.
«Наш младший брат». 1963.
«Итиль — река течет». 1978.
«Әтил суы ака торур» (уйгур телендә, Кытайда). 1992.



Н. Фәттах нәшрият хезмәткәрләре һәм журналистлар белән. 1957.



Н. Фәттах гаиләсе: хатыны Руфинә, улы Алмас һәм кызы Чулпан. 1972.



Н. Фәттах һәм якташы — рәссам Эрот Зарипов (сулда). 1978.



* * *

Көннәрдән-беркөнне Шукбай, акырып елап, әнисе янына килә.

— Нәрсә булды, балакаем?

— Әти ялгыш бармагына чүкеч белән сукты.

— Ә син нигә елыйсың?

— Көлеп җибәргән өчен...



ЭЛФИЯ ӘМИРОВНА класс журналына иелүгә, бүлмәдә чебен очканы да ишетелерлек тынлык урнашты. Ниһаять, аның алтын каләме кемнендер фамилиясендә тукталды:

— Сәлимов.

Классташлар, суга чумарга әзерләнгән кешене хәтерләтеп, тирән сулап куйдылар. Дәреслекләрен шапылдатып яптылар һәм борын эчләрендә генә матәм маршын көйли башладылар. Сәлимов шул көй астында ашыкмыйча гына такта янына чыгып басты, сул кулы белән башын кашыды һәм никтер:

— Әлфия Әмировна, сез бүген бигрәк тә чибәр күренәсез,— дип әйтеп куйды.

Укытучы алтын йөгертелгән күзлеген салып, журнал өстенә куйды:

— Я, Сәлимов, әйдә, сөйли башла, җирле халык анда нәрсә белән шөгыльләнә?

Сәлимов сипкелле борынын тартып куйды һәм:

— Прическагыз да бик матур бүген, минеке кебек түгел инде,— диде ул, керпе энәләре кебек тырпаеп торган чәчләрен сыйпап.

Әлфия Әмировна урыныннан торып, тактага эленгән дөнья картасы янына килеп басты:

— Син, нәрсә, дәрескә әзерләнмәдеңмени?

— Сездән бернәрсәне дә яшереп булмый. Барысын күзләребездән күреп, белеп торасыз, чөнки тәҗрибәгез зур,— диде Сәлимов.

Әлфия Әмировна энҗедәй тешләрен күрсәтеп, матур итеп елмаеп:

— Әй, Сәлимов, Сәлимов! Ярар. Африка кая урнашкан, шуны гына булса да күрсәт инде,— диде.

— Тегендә,— диде Сәлимов, уң кулы белән тәрәзәгә таба күрсәтеп.

— Ярар, утыр, "3"ле сиңа,— диде Әлфия Әмировна.

Тәнәфестә коридорда Сәлимов классташ малайларына:

— Иң шәбе аның күзенә төтен җибәрергә...

Нәкъ шул чак алар яныннан Әлфия апалары узып бара иде.

— Т-с-с-с,— диделәр Сәлимовка малайлар.

— Әй, ишетми ич ул, урман тавыгы кебек, чукрак ул,— диде Сәлимов.

Укытучы апалары бер мәлгә туктап, малайга шундый итеп карады, Сәлимов аның барын да ишетүен аңлады.

Икенче көнне укытучы аны тагын такта янына чакырды.

Малай, ак тукыма кебек агарып:

— Кичә миннән сорадыгыз ич инде!— диде.

— Ә минем бүген дә сине тыңлыйсым килә,— диде Әлфия Әмировна, күзләрен серле итеп кысып.

— Их, сез бигрәк матур итеп елмаясыз инде,— диде Сәлимов һәм тынып калды.

— Тагын нәрсә әйтерсең?— дип коры гына сорады укытучы апалары.

— Тавышыгыз җанга сары май булып ята, бигрәк тә ягымлы тавыш,— дип өстәде Сәлимов.

— Бүген дә дәрескә әзерләнмәдеңмени?

— Сез барысын беләсез, барысын сизәсез,— диде Сәлимов акрын гына.— Нигә мәктәптә эшләп, минем кебекләрне укытып, алма кебек яшь гомерегезне әрәм итәсез... Бу чибәрлегегез белән сезгә киногa төшәргә, я театр сәхнәсендә уйнарга кирәк... Алсу Гайнуллина кебек...

Әлфия Әмировна, башын иеп, өстәлдәге кәгазьгә автокарандашы белән нидер сыза иде. Ул:

— Ярар, бар, урыныңа утыр, Сәлимов, "3"ле,— диде.

Фәридә ВАГЫЙЗОВА.

ХИКӘЯ-БИКӘЯЛӘР язарга бигрәк яратасыз икән. Инде менә ничәнче көн рәттән Бикмүш бабайлар, балыкка барулар турында укый-укый күзләр әлҗе-мөлҗе килә башлады. Бүген "Б"га башланган ике бикәяне тәкъдим итәбез, калганнары газета битләрендә киләчәктә дөнья күрер. Киләсе "Шаянтуй"га сезгә бирем — "С"га башланган бикәяләр җибәрегез. Төп шарт — язган нәрсәгез көлкеле һәм мәгънәле булырга тиеш. Аңлашылдымы?

БАБАЙ БИК БОРЧЫЛА

БУЛАТ БӘБКӘМ! Бәдерниса баласы Бәдрия белән бергә булыгыз. Бик булган бала бит Бәдернисаның Бәдриясе. Байлыклары бар, биясе бар, бакча башларында бормалы Бөрләре, Бөрләрендә балыклары бар. Бергәләшеп балыкка барырсыз. Бәдрия белән Бөр буйларын буйларсыз, бәхетегезне бергә бүлешерсез. Бәбекәчем Бәдрия безгә башлыклар, бияләйләр бәйләп бирер.

Булырсыз бергә бәхетле,
Бәдрия белән Булат.
Болардан булыр бер бәби —
Бәләкәйләре Банат.

Бу бәби булыр бик бай,
Булыр бик булган.
Бормаланган Бөр буйларын
Батырлар белән буйлар.
Бәхетле булыгыз! Бабагыз.

Гөлчәчәк ВӘЛИЕВА.
Кукмара, Зур Сәрдек.

БУФЕТТА

БЕЗ: Бари, Булат, Бибисара, Бибинур, Банат — барыбыз бергә буфетка бардык. Бүген биредә бәрәңге боламыгы, борчак боткасы, башкалар бар бит. Безгә бишебезгә бер булки белән бульон, берәр банан бирделәр-бирүен. Боларның бәясе "болан бәясе" булды. Барыбыз банкротлыкта булганга, беткән баш беткән — Булат бишмәтен, Бибинур балдагын, Бари ботинкаларын, Банат базар билетын, бичара Бибисара бүреген биреп, барыбыз бергә безгә борылдык.

Айсылу ЗЫЯТДИНОВА.
Питрәч, Тат. Тау иле.



— Мә-ә-ә, төш минем урындыктан!
— Мияу, мияу, әйттем мин сиңа, хуҗам, Ульяновскидан агып килгән суны эчмә, дидем.
Н. СЕДОВ фоторәсеме.

* * *

— Нигә сезнең ирегез чукраклыктан дәваланмый?

— Балаларның музыка мәктәбен тәмамлавын көтә.

* * *

Әтисе:

— Хәзер, улым, сиңа катлаулы фәнни сорау: чәйнектә су кайнаганда ни өчен аның борыныннан пар чыга?

Малае:

— Авылдан дәү әти җибәргән хатларны ачып укыр өчен...

* * *

Бер малай фермага килеп:

— Әни бер литр сыер сөте сораган иде,— ди.

— Синең савытың бик кечкенә бит, үскәнем,— диләр аңа.

— Алайса, бер литр кәҗә сөте бирегез...

* * *

— Апа, кәнфит белән сыйланыгыз.

— Рәхмәт, матурым.

— Тәмлеме?

— Искиткеч тәмле.

— Кызык, алайса ни өчен аны эт белән мәче төкереп чыгардылар икән соң?

* * *

— Рөстәм, синең зур үскәч кем буласың килә?

— Генерал булам мин.

— Ә сине сугышта атып үтерсәләр?

— Кем?

— Дошман.

— Ә, алайса мин дошман булам...

* * *

— Әни, әти бүген аванс алганмы әллә?

— Каян белдең?

— Ул тагын ванна бүлмәсендә көзгене кырындыра...

* * *

Укытучы: "Әгәр синең бер миллион акчаң булса, нишләр идең?"— дигән темага инша язарга бирә. Ярты сәгать узуга, Марат кулын күтәрә дә:

— Гафу итегез, Әлфия Әмировна, тагын йөз мең өсти алмыйсызмы?— дип сорый.

* * *

Анатомия дәресендә укытучы:

— Марат, иң соңыннан кешенең кайсы тешләре үсә?— дип сорый.

— Алтын тешләре.

* * *

— Син нигә шулкадәр акырып елыйсың, үскәнем?

— Әни этигә син — фил, диде. Әти әнине тавык дип атады... Мин кем булам соң инде алайса-а-а?!



— Ничәнче трамвай бу?
— Чукрак! Алтынчы маршрут дип әйтеп торам ләбаса!

Сәхифәне
Алмаз ГЫЙМАДИЕВ
әзерләде.



Баш мөхәррир
Ләлә ГЫЙМАДИЕВА
Шеф-мөхәррир
Роберт МИҢНУЛЛИН
Редколлегия: Марат БАРИЕВ, Шәүкәт ГАЛИЕВ, Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ, Ләбибә ИХСАНОВА, Равил РАХМАНИ, Илдар ЮЗЕЕВ.



«Сабантуй»ны оештыручылар — Татарстанның Мәгариф министрлыгы, Яшьләр оешмалары советы, Балалар фонды һәм редакциянең хезмәт коллективы. 1924 —90 елларда «Яшь ленинчы» исеме белән чыкты.
Индекс — 54124. Тираж 16000.



Адрес: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
Телефоннар:
49-36-86, 49-36-90,
49-36-77, 49-36-88,
49-36-94, 49-36-95.

Ярдәм итәргә теләсәгез:
р/счет 700161998/2345716
в Волжско-Камском акционерном банке РКЦ ГЦБ г. Казани МФО 265005
«Для фонда редакции».



Татарстан газета-журналлар нәшрияты типографиясендә басылды
Заказ 2143
Газета ТР Матбугат һәм информация министрлыгында теркәлгән. Теркәү таныклыгының номеры 451. Басарга кул куелды: 1996 ел, 26 февраль, 15 сәгать.